**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

06.09.2023 № 294

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимын бетерү турында**

Азык-төлек ягыннан иминлеккә янаган куркынычны һәм гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү буенча эшләрне тәмамлау белән бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасының Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай һәм Ютазы муниципаль районнарының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертү турында» 2023 елның 3 июлендәге 222 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН